ГЛАВА СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская, д.12, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Иске Каразирек авылы, Совет урамы, 12 йорт, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге составына керүче Иске Каразирек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 15 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Иске Каразирек авылы, Советская урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан Иске Каразирек торак пунктындагы авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Иске Каразирек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Иске Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның якын туганнары (ата-аналары, балалары), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Иске Каразирек торак пунктында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары, бетонлаштыру, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Каразирек торак пунктының

Тукай урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, ПГС салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитетына Яңа Каразирек торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев